**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,**
**Дмитров урамы, 2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**423962, с. Ютаза,**
**ул. Дмитрова, д.2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2021 ел № 22

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 9 ноябрендәге «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Алма-Ата авыл җирлегендә халык җыенын үткәрү турында»гы 16 санлы карарын гамәлдән чыгару турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ХРТ санлы Татарстан Республикасы законы, 2021 елның 28 октябрендәге «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында «2020 елның 19 мартындагы 208 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 1006 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары,2019 елның 17 июлендә Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 10 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы “Ютазы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, 2020 елның 9 октябрендә Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 7 санлы карары белән кабул ителгән «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 9 ноябрендәге «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Алма-Ата авыл җирлегендә халык җыенын үткәрү турында»гы 16 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов